# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

30 октябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җайланмалар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу) .

3.Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче, Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы — И.М.Мухаметзянов

КАКРЕ-ЕЛГИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ